Ким авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 10 23.04.2021г

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында»гы 01.02.2021 елның 2 карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау турында» гы 01.02.2021 елның 2 номерлы карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү:

1.1. 6 пунктның 6.1.пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук күпфатирлы йортлар, торак йортлар (территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).

2. Әлеге карарны Ким авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Ким авыл Җирлеге Башлыгы
авыл җирлеге Башлыгы В. В. Синчугов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ